РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр, пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 47

2026 елның 15 сентябре

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы, Түбән Кама муниципаль районы Советы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1.Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Депутатның вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Түбән Кама муниципаль районы Советының беренче утырышы тулы хокуклы составында узган көннән туктатыла.»;

3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатның вәкаләтләре «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла.».

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Советының җирле үзидарә, регламенты һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
Районы Башлыгы

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

Р.И. Беляев